**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**29.10. 2019 ел.** **№101**

Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 ноябрендә кабул ителгән 45 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында (2018 елның 27 апрелендәге 58 номерлы карар үзгәрешләре белән.)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 29.09.2009 елдагы 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 ноябрендәге 45 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 2 пунктында түбәндәге сүзләр өстәргә: "(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)";

2. Беловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (httr://aksubayevo.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Беловка авыл җирлеге Советы рәисе И. Р. Мәхмүтов